Квест уен

Тема: «Минем туган җирем”

Бурычлар:

1. Туган авылыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү.

2. Үстерешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

3. Балаларның Ватаныбыз, республикабыз(шәһәр һәм авыл) һәм аның символикасы турында мәгълүматларын арттыру.

Сүзлек: хат

Җиһазлар: слайдлар,фотосүрәтләр,хат.

Эшчәнлек барышы.

1. Исәнмесез, балалар. Кунаклар белән исәнләшик әле.

-Хәерле иртә. Бер-берегезгә карап елмаеп, җылы хисләребезне бүләк итик әле.

- Тәрбияче: Үскәннәрем минем, балалар бакчасына эшкә килгәндә, хат ташучы безгә дип адресланган хат бирде. Менә ул хат(күрсәтә). Карыйк әле, нинди хат икән бу? Сез укый беләсезме?

Хатны уку: “Исәнмесез, балалар! Сезгә мәскәү балалары хат яза. Без Шәле авылына үзебезнең дусларыбыз янына танышырга килмәкче идек. Сезнең туган авылыгыз белән якыннанырак танышасыбыз килә. Зинһар өчен,булышыгыз әле, балалар!”

-Мәскәү дусларыбызга булышабызмы?

-Балалар: әйе.

-Тәрбияче: мин аларга хат язып җибәрәм. Без сезнең килүегезгә бик шат дип.

-Балалар! Мәскәүдән килүче балаларны үзебезнең туган җиребез белән таныштырырга нинди белемнәребез бар икән, карап үтик әле.

Балалар ,әйдәгез искә төшерәбез, безнең туган җиребездә нинди ерткыч хайваннар бар? (куян, төлке, бүре....)

Менә шул ертычларның берсе безнең уен кораллары янында утыра. Эзләп карыйкмы? (эзлиләр) Молодцы таптык. Монда нәрсә дип язылган икән?

-Без нинди республикада яшибез?

-Башкалабыз ничек атала?

Молодцы ,акыллылырым, дөрес җавап бирдегез.

-Балалар, безнең Татарстаныбызның символы, флагыбыз бар. Ул нинди төсләрдән тора?(балаларның җавабы)

Флагны без туган ягыбыз почмагыннан таба алабыз(эзлиләр)

-Безнең районыбызның исеме ничек?

-Безнең авылның исеме ничек?(б.җавабы)

-Балалар сез бик уңган балалар икән.

-Балалар без нинди язучыларны беләбез? (Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш)

-безнең китаплар илендә, А.Алишның “Куян кызы” әкият китабынан биремне табыйк әле. Менә икән бит,молодөы, таптыгыз да.

(Мишә,Кама елгасы рәсемнәре. Ике командага бүленеп, кисмә рәсемнәрне дөрес итеп җыю)

-Балалар, таныйсызмы, нинди елгалар килеп чыкты?(Мишә,Кама)

Слайдлар карау. Елгалар.

Безнең төркемдә күлләр бармы соң?

менә шунда тагын бер бирем бар.

Тел шомарткыч. (Б) авазы

Бу елгада борылма да борылма,

Борылма дип юлдан кире борылма.

(3 тапкыр бергә әйтәләр, 2-3 бала берәм-берәм дә әйтә)

-Татарстанда бик күп төрле халыклар яши (санап китү) алар бер-берсе белән дус тату яшиләр. Туган як почмагында безнең төрле милләт курчаклары бар, карыйк әле, балалар. (Курчаклар янында бирем була).

“Башын мин әйтәм, ахырын син әйт уены”

1. Кош канаты белән (кеше дуслары белән көчле)

2. Дустың булмаса, эзлә(тапсаң югалтма)

3. Күмәк күтәрсә, (күлне күчерер)

4.Ялгыз агачны(җил сындыра)

Мәгънәләрен аңлату, балалар әйтә, адымлап алга баралар.

-Балалар, әйдәгез , дус, тату булып, җырлы уен “Яшел яулык” татар халык уены уйнап алыйк.

Балалар кулларын артка куеп түгәрәккә басалар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә.Аның кулында кулъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, җырлап йөри:

Кулъяулыгым яшел, яшел,

Яшел чирәм астында.

Сиздермичә ташлап китәм

Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә яулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Яулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итә. Әгәр ул тоткарланып торса яки яулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

Менә ял итеп, уйнап та алдык балалар.

Безнең авыл зур,матур. Исеме ничек әле авылыбызның? Тагын бер биремне туган як почмагыннан табыйк әле.

Менә ул,таптык. “Бу урынны таныйсызмы?” дидактик уены (слайдлар карап,рәсемне танып бер-ике җөмлә белән әйтеп китергә)

-Әйдәгез балалар, үзебезнең Шәле авылының, матур, истәлекле урыннарын искә алып, алар турында сөйләп китик әле.(Балаларның җаваплары)

-Молодцы, балалар! Мәскәү балалары безнең туган җир турында бик күп мәгълүматлар белеп,танышып китәрләр.

Рәхмәт балалар, сез бик тырыштыгыз!